РУКОВОДИТЕЛЬ
ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО
КОМИТЕТА КУРАЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КУРАЛОВО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
ҖИТӘКЧЕСЕ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

15.03.2021 | с. Куралово | 05 А

**Куралово авыл җирлегендә 2021нче елның язгы чорында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында**

"Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" 2007нче елның 8нче ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында" 2009нчы елның 3нче августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, «Төбәк яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау хакында» 2013нче елның 31нче маендагы 372нче номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Куралово авыл җирлеге Уставына нигезендә, тискәре табигать - климат шартлары барлыкка килгән чорда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының конструктив элементларының сәләтен киметүне булдырмау максатларында, Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021нче елның 1нче апреленнән 30нчы апреленә кадәр Куралово авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында 6 тоннадан артык массасы булган йөк белән яки йөксез транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне кертергә (алга таба-язгы чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү).

2. Хәрәкәтне вакытлыча чикләү 3.12 "Транспорт чарасына туры килә торган массаны чикләү" юл билгеләрен урнаштыру юлы белән Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләре белән каралган өстәмә мәгълүмат (табличкалар) 8.20.1 һәм 8.20.2 "Транспорт чаралары тибы" тамгалары белән гамәлгә ашырыла.

3. Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлегенең ЮХИДИ бүлегенә Югары Ослан муниципаль районы Куралово авыл

җирлеге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү режимын үтәүне контрольдә тотуны оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Куралово авыл җирлеге Башкарма комитет җитәкчесе Т. Ю. Тимиряева